| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

12.05.2021 Казан ш. № 75-4/э-2021

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «2018-2020 елларга Татарстан Республикасы территориясендә челтәр оешмалары арасында үзара исәп-хисап ясау өчен электр энергиясен тапшыру хезмәтләренә хосусый тарифлар билгеләү турында» 15.12.2017 № 3-13/э карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Югары судының 16.12.2020 №3а-647/2020 карарын һәм Гомуми юрисдикциядәге дүртенче апелляция судының 07.04.2021 №66а-826/2020 карарын үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «2018-2020 елларга Татарстан Республикасы территориясендә челтәр оешмалары арасында үзара исәп-хисап ясау өчен электр энергиясе тапшыру хезмәтләренә хосусый тарифлар билгеләү турында» 15.12.2017 №3-13/э карарына (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 14.12.2018 №3-14/э, 12.12.2019 №3-17/э, 19.12.2019 №3-25/э карарлары керткән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 нче кушымтаның 2 нче пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «2 | «Интеграция» чиктәш челтәр компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте – «Сетевая компания» ачык акционерлык җәмгыяте | 2018 | 225 780,63 | 54,28 | 0,52466 | 225 780,63 | 56,45 | 0,52683 |
| | | 2019 | 223 442,43 | 81,93 | 0,53838 | 223 442,43 | 87,56 | 0,54401 |
| | | 2020 | 337 545,70 | 59,21 | 0,72052 | 337 545,70 | 59,21 | 0,72052»; |

3 нче кушымтаның 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| «2 | «Интеграция» чиктәш челтәр компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте – «Сетевая компания» ачык акционерлык җәмгыяте | 2018 | 71 890,36 |
| | | 2019 | 109 375,96 |
| | | 2020 | 180 023,98». |

2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2020 елның 1 гыйнварыннан 2020 елның 31 декабренә кадәр барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач гамәлгә керә.

Рәис А.С.Груничев